**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авылында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре № 2

**2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге Иске Куак авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлеге Иске Куак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балачактан инвалидлар, 1, 2 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:

Иске Куак авылында Заварыкин урамында урнашкан зиратка каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар сатып алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы оештыру, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру:

Иске Куак авылы территориясендә үлән чабу;

3) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Иске Куак авылында, Заречная урамында, Заварыкин урамында вак таш белән капланган юлларны чокырлы ремонтлау.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы, 7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар ыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы И.Н.Сушкова